**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ № _______

Актаныш муниципаль районының Актаныш авылы урамнары буенча халыкара класслы спорт мастеры Фирая Солтанова-Жданова Кубогына җиңел атлетика эстафетасы үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы һәм «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, халыкара класслы спорт мастеры Фирая Солтанова-Жданова Кубогына җиңел атлетика эстафетасын үткәргәндә куркынычсызлыкны тәэмин итү максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 23 апрелендә 09.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр түбәндәге урамнарда автотранспорт хәрәкәтен ябарга:

- Юбилей урамы, Юбилей урамы киселешеннән алып Татарстан урамына кадәр;
- Татарстан урамы белән киселешеннән алып, Җиңүнең 30 еллыгы урамы белән кисешкәнгә кадәр;
- Ленин проспекты, Ленин проспекты киселешеннән алып Комсомол урамына кадәр;
- Комсомол урамы, Комсомол урамы киселешеннән алып Җиңүнең 30 еллыгына кадәр.

2. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районы буенча бүлегенә, ябылган участокларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов